**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 18 октябрь № 755

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән көндезге формада белем алучы студентларга дәүләт академик стипендиясен, студентларга дәүләт социаль стипендиясен, аспирантларга, ординаторларга, ассистент-стажерларга дәүләт стипендиясен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 27 февраль, 121 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән көндезге формада белем алучы студентларга дәүләт академик стипендиясен, студентларга дәүләт социаль стипендиясен, аспирантларга, ординаторларга, ассистент-стажерларга дәүләт стипендиясен билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип санау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән көндезге формада белем алучы студентларга дәүләт академик стипендиясен, студентларга дәүләт социаль стипендиясен, аспирантларга, ординаторларга, ассистент-стажерларга дәүләт стипендиясен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 27 февраль, 121 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән көндезге формада белем алучы студентларга дәүләт академик стипендиясен, студентларга дәүләт социаль стипендиясен, аспирантларга,

ординаторларга, ассистент-стажерларга дәүләт стипендиясен билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 нче пунктка «ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затлар,» сүзләреннән соң «уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затлар,» сүзләрен, «Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының эчке гаскәрләрендә,» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрендә,» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы белән контракт буенча укучы В.И.Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының юридик факультеты студентлары өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең махсус дәүләт стипендиясен гамәлгә кую турында» 1995 ел, 18 май, 301 нче;

«Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсендәге дәүләт учреждениеләре аспирантларына стипендияләр турында» 2013 ел, 26 октябрь, 798 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков